СССР төзелүнең 60 еллыгына

Шагыйрь данлаган җир

«Восток»

колхозы

СССР ТӨЗЕЛҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫ ХӨРМӘТЕНӘ СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ АЛДЫНГЫЛАРЫ:

* Комбайнчы Р. Фазлетдинов.
* Сыер савучы Р. Акбарова.
* Тракторчы А. Алкин.
* Комбайнчы А. Валитов.

Бу җир үзе мең әкият,
Кайда барма—монда гел алтын:
Куллар алтын, басулары алтын,
Кешеләрнең җаны мең алтын.

НАҖАР НӘҖМИ.

Һәр эшкә дә уңганнар

Сез кайдан? — дип
сорасагыз,
Безнең авыл — Миңеште.
Иллә-мәгәр Миңештегә
Колхоз бигрәк килеште.

Бу шигъри юлларны Миңеште авылыннан якташыбыз, Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми язган. Шушы сүзләргә язылган җыр бу якларда зур популярлык алган. Чыннан да, авыл кешеләренә чын халык власте булган Совет власте һәм колхоз бигрәк килеште. «Ленин», «большевиклар», «коммунизм» — бу сүзләр алар өчен кадерле һәм аңлаешлы. Бөек Ленин җитәкчелегендәге большевиклар партиясе, Совет власте аларны гасырлар буена килгән караңгылыктан, бөлгенлектән һәм артталыктан яктыга, мул тормышка алып чыкты.

1938 елда СССР Верховный Советы сессиясендә чыгыш ясап, БАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Р. К. Ибраһимов бу авыл язмышы турында менә нәрсәләр сөйләгән:

«Башкорт АССРның Дүртөйле районында Миңеште авылы бар. 1913 елда ул иң хәерче авылларның берсе булып исәпләнгән. Андагы 160 хуҗалыкның 23 ендә — ат һәм сыер, ә 35 ендә хәтта вак терлек тә булмаган. Авыл кешеләренең күбесе укый-яза белмәгән, хәерчелектә көн күргән...»

1931 елда авыл ярлылары коллектив хуҗалыкка берләшкәннәр һәм 1935 елда инде колхоз миллионер хуҗалыкка әверелгән. Колхозга «Урал» дигән исем бирелгән. Бу исемгә авылның чал Урал тармакларына урнашуы гына түгел, бәлки тәүге колхозчыларның үз коллектив хуҗалыкларын Урал таулары биеклегендәге үсештә күрергә дигән олы максаты гәүдәләнгән. Авыл халкы гаять зур омтылыш һәм хезмәт дәрте белән яшәгән. Районда беренчеләрдән булып, анда электр станциясе төзелгән, крестьян йортларына электр уты үткәрелгән, клуб төзелгән.

«Урал» колхозы турында яхшы истәлек авыл эшчәннәре күңелендә бүген дә саклана. «Урал» — бүген колхозның стена газетасы әнә шундый исемне йөртә.

Тәүге колхозчыларның матур хыяллары тормышка ашты. Бүгенге көндә үзенең экономик һәм социаль үсеше белән «Восток» колхозы ул еллар крестьяннарының иң матур хыялларыннан да уздырды. Әйтик, 1932 елда 527 гектардагы бөртеклеләрнең һәр гектарыннан нибары 6,6 центнер уңыш җыеп алынган булса, үткән бишьеллыкта 2 мең гектардагы бөртекле культураларның һәр гектары елына уртача 19,3 центнер уңыш бирде. Терлекчелек продуктларын җитештерү күләме чагыштыргысыз артты. Быел җиде айда 10 724 центнер сөт җитештерелде. Бу 1975 ел буена җитештерелгән күләмдә дигән сүз. 1979 елдан башлап колхозда һәр сыердан уртача савым 3 мең килограммнан артык тәшкил итә.

Бүгенге үрләр колхозчыларның тырыш хезмәте, хуҗалыкны оста алып бару һәм илебез халыкларының зур ярдәм күрсәтүе аркасында яуланды. Басуларда уңышны Украинада эшләнгән комбайннар җыеп ала, минераль ашламалар һәм үсемлекләрне саклау өчен химик средстволар Мәскәү һәм Казахстан заводларыннан кайтарыла. Башкорт селекционерлары чыгарган сортлар белән беррәттән Рязань өлкәсендә чыгарылган «московская-35» сортлы сабан бодае да игелә. Терлекчелек фермаларында гаять зур илебезнең төрле заводларында эшләнгән механизмнар урнаштырылган.

Бу як кешеләре үзләре дә башка халыклар белән туганнарча дуслык һәм бердәмлек үрнәген күрсәтәләр. Сугыш елларында Миңеште авыл Советына караган авыллардан 530 кеше кулларына корал тотып, илебез халыклары азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәште, шуның 291е батырларча һәлак булды. Танкист лейтенант Арслан Ситдиков латыш җирендә ятып калды.

«Восток» колхозы эшчәннәре илебезнең булачак юбилеен лаеклы каршыларга әзерләнә. Шушы данлыклы дата хөрмәтенә дәүләткә 11500 центнер сөт, 2350 центнер ит сатарга йөкләмә алдылар. Шик юк, бу йөкләмәләр намус белән үтәләчәк. Чөнки шагыйрь дә үз якташлары турында, һәр эшкә дә уңганнар, дип яза.

Саннар һәм фактлар

* 1962 елда колхозның гомуми куәте 258 ат көчле 11 тракторы һәм йөк күтәрүчәнлеге 13,5 тонна тәшкил иткән 5 автомашинасы булган. Ә хәзер хуҗалыкта гомуми куәте 2350 ат көчле 29 трактор, йөк күтәрүчәнлеге 90 тонна тәшкил иткән 22 йөк автомобиле бар.

* Былтыр авыл хуҗалыгының тулай продукциясе 1962 ел белән чагыштырганда 3 тапкырга артыграк җитештерелде.

* Моннан 20 ел элек колхозда шартлыча исәпләгәндә 1008 терлек булган, хәзер исә аларның саны 2417 башка җитә.

* Колхоз партия оешмасы 65 коммунистны берләштерә. Күптән түгел яшь механизатор Виктор Баязитов һәм сыер савучы Альбина Дәүләтшиналар партия сафына кабул ителде.

* Былтыр 9 колхозчы түләүсез путевкалар буенча Бөтенсоюз санаторийларында ял итте. Алар арасында механизаторлар Борис Әгъзамов, Рәрүф Фазлетдинов, колхозчы Маня Майдановалар бар иде.

* 1962 елда колхоз игенчеләре бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 14 центнер уңыш алган иде. 1982 елда мул уңыш үстерелде: бөртеклеләрнең һәр гектары 26,3 центнер уңыш бирде.

Саннар һәм фактлар

* 1962 елда колхозның гомуми куәте 258 ат көчле 11 тракторы һәм йөк күтәрүчәнлеге 13,5 тонна тәшкил иткән 5 автомашинасы булган. Ә хәзер хуҗалыкның гомуми куәте 2350 ат көчле 29 трактор, йөк күтәрүчәнлеге 90 тонна тәшкил иткән 22 йөк автомобиле бар.

* Былтыр авыл хуҗалыгының тулай продукциясе 1962 ел белән чагыштырганда 3 тапкырга артыграк җитештерелде.

* Моннан 20 ел элек колхозда шартлыча исәпләгәндә 1008 терлек булган, хәзер исә аларның саны 2417 башка җитә.

* Колхоз партия оешмасы 65 коммунистны берләштерә. Күптән түгел яшь механизатор Виктор Баязитов һәм сыер савучы Альбина Дәүләтшиналар партия сафына кабул ителде.

* Былтыр 9 колхозчы түләүсез путевкалар буенча Бөтенсоюз санаторийларында ял итте. Алар арасында механизаторлар Борис Әгъзамов, Рәрүф Фазлетдинов, колхозчы Маня Майдановалар бар иде.

* 1962 елда колхоз игенчеләре бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 14 центнер уңыш алган иде. 1982 елда мул уңыш үстерелде: бөртеклеләрнең һәр гектары 26,3 центнер уңыш бирде.

Дуслык телендә

«Үзем башкорт, рус егетен яраттым гомерлеккә,» — дип җырлана башкорт җырларының берсендә. Баргызбаш авылыннан рус егете Александр Ромашовка тормышка чыккан Зөһрә дә үзе турында әнә шулай җырлый. Алар авылда йорт салып керде, икесе дә колхозда эшли. Яңа йортның тәрәзәләре милләте буенча башкорт булган бригадир Рәфил Фазлетдиновлар ихатасына карый. Хат ташучы чуваш Нина көн саен аларның йортларына газеталар һәм хатлар китерә. Үз язмышын ул башкорт Хәмбәл Гайсин белән бәйләгән. Авылда татарлар, марилар яши. Әнә шулай бер авылда төрле милләт кешеләре бәхетле тормыш корган. Гомумән, колхоз составы буенча күпмилләтле. Биредә татар-башкорт авыллары Миңеште һәм Баргызбаш ,рус авылы Успеновка, мари авылы Ярмия бар. Колхозда удмуртлар һәм украиннар да яши. Алар барысы да бер җирдә җиң сызганып эшли, бер телдә — дуслык һәм туганлык телендә сөйләшә.

Талантлы кешеләр җире

Безнең лицей! Без укыган
мәктәп...
Кемнеңдер ул булган келәте.
Ләкин шунда мин тәү
күрдем түрдә
Эленеп торган Ленин
сурәтен.

Бу мәктәп бүген дә калкулыктан һәр тарафка күренеп тора һәм, барыннан да элек, үзенең элекке укучылары белән күренекле ул. Анда илебездәге күпмилләтле әдәбият горурлыгы булган Наҗар Нәҗми укыган. Үзенең шигъри иҗатына туган ягының күпсанлы чишмәләреннән, гаҗәеп матур табигатеннән илһам алган ул.

Чыннан да, Миңеште җире талантлы кешеләргә бай. Техник фәннәр кандидаты Хәвәс Нуретдинович Низамов, авиация институты доценты Фидарис Гыйльванович Тимершин һәм медицина фәннәре кандидаты Габбас Габдуллович Хафизовлар зур фән юлыча шушы яклардан чыкканнар. БАССР мәктәпләренең атказанган укытучылары Әдилә Кадыйровна Абдукаева һәм Ирина Корбановна Шәрәфневалар халык мәгарифе өлкәсендә уңышлы эшлиләр. Республиканың атказанган агрономы Әнгам Әүхәдиев белән дә горурлана мәктәп. Колхозчылар арасында республиканың атказанган терлекчесе савучы Сөгъдә Гарипова, орденлы тракторчы Хәмит Гафиятуллин эшли. Ә Рәрүф Фазлетдинов, Рәдүс Ситдиков, Александр Алкин, Иманян Николаев, Алексей Валитов, Виталий Султанаев кебек игенчелек осталарын талант ияләре белән чагыштырырлык түгелмени? Һәр сыердан сөт савып алу буенча тәүгеләрдән булып дүрт мең үрен яулаган савучы Рәмилә Акбарова, район буенча ярышларда чөмме һәрчак алдынгылар сафында булган дуңгыз караучылар Разия Сәлимова һәм Флүрә Исламовалар да үз эшләренең талантлы осталары булып тора. Колхозның төп байлыгын тәшкил итүче әнә шундый уннарча намуслы эшчәннәрнең исемнәрен санап үтәргә мөмкин булыр иде. Аларның үзенчәлекле талантлары фәкать Октябрь кояшы астында, Совет власте чорында гына тулысынча ачылды.

x x x

Ленин васыятьләренә турылыклы булып, «Восток» колхозы эшчәннәре сөекле Ватаныбызны — Совет Социалистик Республикалар Союзын тагын да матуррак һәм куәтлерәк итү өчен үзләренең бөтен көчләрен, талантларын һәм осталыкларын биреп эшлиләр.

Р. СИТДИКОВ



Комбайннар уңыш җыйганда.



Ашлык «фабрикасы».



Колхозчылар әнә шундый мәһабәт йортларда яшиләр.
Р. Ногъманов фотолары.